РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РАСПОРЯЖЕНИЕ

БОЕРЫК

«10» февраля 2021 с. Тюлячи № 21

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның
17 июнендәге 443 номерлы «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен раслау турында» карары белән расланган 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында белем алучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен 2021-2022 елларда гамәлгә ашыру буенча Теләче муниципаль районының чаралар планын раслау хакында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нең 2021 елның 3 февралендәге 32 номерлы хатын караганнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 декабрендәге 2581-р номерлы боерыгы нигезендә,

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен раслау турында» карары белән расланган 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында белем алучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен 2021-2022 елларда гамәлгә ашыру буенча Теләче муниципаль районының чаралар планын (алга таба - план), кушымта нигезендә, расларга.

2. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.):

2.1. Планны гамәлгә ашыру буенча җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.

2.2. Квартал саен Планны тормышка ашыруга анализ ясарга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«10» февраль 2021 № 21
боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен раслау турында» карары белән расланган 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында белем алучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен 2021-2022 елларда гамәлгә ашыру буенча Теләче муниципаль районының чаралар планы

| № т/б | Чаралар атамасы | Үткәрү вакытлары | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. Тәрбия өлкәсендә оештыру-идарә механизмнарын камилләштерү | | | |
| 1.1. | Тәрбия инфраструктурасын анализлау | | |
| 1.1.1. | Мәктәпкәчә яшьтәге ата-аналарга методик, психологик-педагогик, диагностик һәм консультатив ярдәм күрсәтү буенча консультатив эшне үстерү | | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре |
| 1.1.2. | Мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе кысаларында тәрбиянең актуаль мәсьәләләрен карау | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.1.3. | Мәгариф оешмаларының балигъ булмаганнар белән эшләгәндә профилактик программаларны куллану буенча мәдәният өлкәсендә тәрбия эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.1.4. | Мәгариф хезмәткәрләренең киңәшмәләрендә экологик тәрбия мәсьәләләрен карау | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.1.5. | Өстәмә белем бирү системасының инфраструктурасы белән тәэмин ителешенә анализ үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», өстәмә белем бирү учреждениеләре |
| 1.2. | Тәрбия үсеше өлкәсендә оешмалар эшчәнлегенә мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү | | |
| 1.2.1. | Тәрбия эшләре буенча директор урынбасарларының һәм сыйныф җитәкчеләренең, өстәмә белем бирү педагогларының, район методик берләшмәләре эшчәнлеге кысаларында, семинар - конференцияләр үткәрү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», Мәгариф учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре |
| 1.2. | Белем бирү процессында катнашучыларны тәрбияләү, психологик яктан тәэмин итү, эшчәнлек кысаларында семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | үткәрү: | | |
| 1.2.3. | Тәрбия системасын үстерүнең актуаль проблемалары буенча республика съездларында, конференцияләрендә, түгәрәк өстәлләрендә һәм тәрбия өлкәсе белгечләренең башка чараларында катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.3. | Балалар-ата-аналар һәм гаилә мөнәсәбәтләре, балаларны тәрбияләү мәсьәләләрендә компетенцияләрне арттыру өлкәсендә ата-аналарга (законлы вәкилләргә) белем бирү буенча чараларны мәгълүмати-методик тәэмин итүне оештыру | | |
| 1.3.1. | Гаилә тәрбиясе һәм яшь психологиясе нигезләре буенча ата-аналар лекторийлары | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.3.2. | Балалар белән профилактик чаралар һәм ата-аналар белән очрашулар үткәрү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.3.3. | Балигъ булмаганнарның үз-үзләрен девиант тотышын профилактикалау буенча ата-аналар һәм педагогик хезмәткәрләр өчен методик материаллар эшләү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.3.4. | Биләп торучы гаиләләргә медицина, хокукый, икътисадый, педагогик характердагы мәсьәләләр буенча консультация бирү | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 1.3.5. | Тәрбия өлкәсе белгечләренең республика, региональ семинар-киңәшмәләрендә һәм башка чараларында катнашу | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 1.3.6. | Тәрбиягә бала алган гаиләләрнең республика форумында катнашу | Ел саен | Опека һәм попечительлек секторы |
| 1.3.7. | Муниципаль ата-аналар җыелышлары, киңәшмәләр, семинарлар үткәрү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.3.8. | Балалар-ана мөнәсәбәтләре мәсьәләләрендә ата-аналарның компетентлыгын арттыру мәсьәләсе буенча мәгариф системасы һәм яшьләр сәясәте өлкәсе педагог-психологларының уртак семинарларын уздыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 1.3.9. | Мәгариф оешмалары педагогларының балалар-ата-аналар һәм гаилә мөнәсәбәтләре, балаларны тәрбияләү мәсьәләләре буенча уртак семинарларда катнашуын оештыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәдәният бүлеге |
| 1.3.10 | "Балалар ышаныч телефоны" һәм психологик хезмәт эшчәнлеген популярлаштыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.4. | Гражданлык, патриотик, рухи-әхлакый, хокукый, физик, хезмәт, экологик тәрбия, профориентация, балаларны мәдәни мираска җәлеп итүгә юнәлдерелгән балалар фестивальләре, конкурслары, ярышлары һәм башка чаралар үткәрү | | |
| 1.4.1. | Халыкара туган тел көненә багышланган ункөнлекне оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәдәният бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.2. | Туган тел көнен һәм рус теле көнен оештыру һәм уздыру | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәдәният бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.3. | Халыклар бердәмлеге көненә багышланган тантаналы чаралар, сыйныф сәгатьләре | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәдәният бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.4. | "Зур этнографик диктант" бөтенроссия агарту акциясендә катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.5. | Белем бирү оешмаларында "Масленица", "Нәүрүз", "Сабантуй" татар бйрмен, "Каравон" рус бәйрәме, "Питрау" керәшен мәдәнияте традицион халык бәйрәмнәрен популярлаштыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.6. | Татарстан һәм татар халкы тарихы буенча республика олимпиадасында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.7. | Муниципаль этапны оештыру һәм туган телләр буенча республика олимпиадаларында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.8. | Татар теле буенча халыкара олимпиадада катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.9. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының коррупциягә каршы сәясәтен тормышка ашыру гамәлләре турында хисаплар | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.10. | Террорчылыкка каршы, патриотик тематикага креатив интернет-контент булдыру буенча гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында республика конкурсында муниципаль этапны оештыру | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.11. | Гомуми белем бирү оешмалары арасында муниципаль этапларны оештыру һәм үткәрү, Бөтенроссия физкультура чараларының республика этапларында, шул исәптән "Президент ярышлары" Бөтенроссия спорт ярышларында, "Президент спорт уеннары" Бөтенроссия мәктәп укучыларының спорт уеннарында катнашу | Ел дәвамында | Балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.12. | Белем бирү учреждениеләре укучылары арасында "Хезмәткә һәм | Ел саен | Балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге, мәгариф |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оборонага әзер" (ГТО) фестиваленең республика этабын оештыру һәм үткәрү | | учреждениеләре |
| 1.4.13. | Татарстан Республикасы укучылары арасында Туриадада (Спартакиадада) катнашу | Ел саен | Балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.14. | Яшь армиячеләр арасында "Туган як" патриотик видеороликлар республика конкурсында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.15. | Муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү, мәктәп музейларының "Яшь армиячеләр-хәрби дан сакчылары" смотр - конкурсының республика этабында катнашу" | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.16. | Яшь Армия отрядлары арасында Ватанның хәрби тарихын белү буенча олимпиаданың республика этабында муниципаль этапны оештыру һәм катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.17. | Вахтаны иң яхшы оештырган "Пост № 1" яшь армияче отрядлары арасында сугышчан дан һәм Ватан Геройлары көннәрендә Мактау каравылы истәлегенә республика конкурсында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.18. | "СТРЕЛА-2М" укыту-тренировка комплексын алуга "ЮНАРМИЯ" ВВПОД җирле штабларының республика конкурсының муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.19. | Муниципаль этапны оештыру һәм уздыру, хокук бозуларны профилактикалауның мәктәп отрядлары конкурсының республика этабында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.20. | Идел буе халыклары "Республика фольклор конкурсында катнашу" | Ел саен | Балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.21. | Муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү, "Без бергә" балалар халык иҗаты фестиваленең зона һәм республика этабында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.22. | Теләче муниципаль районында олимпиада хәрәкәтен үстерү буенча "юл картасын" тормышка ашыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.4.23. | Сәләтле балалар өчен ел саен үткәрелә торган интеллектуаль ярышларда һәм чараларда, шул исәптән сәләтле балалар өчен республика җәйге профильле сменаларында катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.24. | Сәләтле балаларның "Мәктәп белемнәреннән фәнни эзләнүгә" | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республика фәнни-гамәли конференциясендә катнашу | | |
| 1.4.25. | Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының аерым этапларына әзерлек кысаларында укыту-тренировка җыеннарында һәм профильле сменаларда катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.26. | Махсус проектларны тормышка ашыруда катнашу - "Олимпка юл", "Ватанга хезмәт итәм! Халыкка хезмәт итәм!" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет гомуми белем бирү оешмаларының 7-11 сыйныф укучылары арасында | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.27. | Балалар техник иҗаты фестивалендә катнашу | Ел саен | Балалар иҗат үзәге |
| 1.4.28. | Санитар-экологик икеайлык кысаларында "Экояз" республика акциясен оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.4.29. | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында "Мәктәп экопатруле" конкурсының республика этабында муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.4.30. | Татар теле буенча сөйләм практикасы белән милли-мәдәни профильнең төбәкара сменаларында катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.31. | Мәктәп укучыларының Россия Федерациясе халыклары телләрендә укулары һәм фәнни-гамәли конференциясендә катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.32. | "Шәһәрләр-нәсел агачы" төбәкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен муниципаль конкурс оештыру һәм үткәрү" | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.33. | Каюм Насыйри исемендәге төбәкара яшүсмерләр фәннитикшеренү укуларында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.34. | Муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү, "Илһам" ("Вдохновение") Бөтенроссия яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.35. | "Сәйяр" балалар яшүсмерләр театрлары фестиваленең республика этабында катнашу, муниципаль этапны оештыру һәм уздыру | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.36. | "Созвездие-Йолдызлык" республика ачык яшьләр эстрада фестивалендә катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәдәният бүлеге, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, балалар иҗат үзәге, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.37. | "Ел лидеры" балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре республика конкурсында катнашу | Ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.38. | "Сәләт" халыкара яшьләр белем бирү форумында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.4.39. | "Форпост" хокук тәртибе отрядларының укыту-тренировка җыеннарында катнашу | Ел саен | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.5. | Балалар иҗтимагый берләшмәләре, балалар һәм өлкәннәр иҗтимагый үзидарәсенең хәрәкәтләрен һәм башка рәвешләрен оештыру-методик ярдәм белән тәэмин итү, шул исәптән: Россия мәктәп укучылары хәрәкәте, "Форпост" отрядлары, хокук бозуларны профилактикалау отрядлары; ЮИД отрядлары, татулаштыру мәктәп хезмәтләре, яшь туган якны өйрәнүчеләр берләшмәләре, экологлар, туристлар, тарихи-эзләнү отрядлары, ата-аналар берләшмәләре, гаиләне саклап калу һәм яңадан торгызуга, гаилә һәм әхлакый кыйммәтләрне саклауга һәм торгызуга ярдәм итү | | |
| 1.5.1. | Балалар иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген координацияләү, шул исәптән "Татарстан варислары берлеге", республика конкурслары, акцияләр, профильле сменалар үткәрү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.2. | "Россия мәктәп укучылары хәрәкәте" гомумроссия иҗтимагый - дәүләт балалар-яшүсмерләр оешмасы үсеше | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.3. | Яшь армия хәрәкәтен үстерү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.4. | Яшь хәрәкәт инспекторларының мәктәп отрядларын үстерү (ЮИД) | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.5. | "Татарстан Республикасы балалар оешмалары советы" региональ иҗтимагый оешмасы эшчәнлеге кысаларында чараларны оештыру һәм проектларны гамәлгә ашыру | Ел дәвамында | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.6. | Юннат хәрәкәте үсеше | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.7. | "СМС-балалар" наркотикларга каршы проектны үстерү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», балалар иҗат үзәге, мәгариф учреждениеләре |
| 1.5.8. | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында этиләр советлары эшчәнлегенә оештыру-методик ярдәм күрсәтү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.5.9. | Мәктәп бердәмләшү хезмәтләре эшчәнлеген үстерү | 2021 ел | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 1.5.10. | Конфликтларны профилактикалау һәм хәл итүнең медиатив технологияләре турында гомуми белем бирү оешмалары директор- | 2020-2021 еллар | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | лары өчен республика семинарларында катнашу | | |
| 2. Тәрбиягә бала алган гаиләләр, тәрбиягә бала алган ата-аналар, интернат учреждениеләрне тәмамлаучылар белән тәрбия өлкәсендә эшне камилләштерү | | | |
| 2.1. | Ата-ана каравыннан мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче гражданнарга психологик-педагогик һәм гаилә тәрбиясенең башка мәсьәләләре буенча консультация бирү | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.2. | Тәрбиягә бала алган ата-аналар мәктәбе белгечләренең, Татарстан республикасының тәрбиягә бала алган гаиләләрен күзәтү хезмәтләренең һәм Татарстан Республикасы балалар йортларын тәмамлаучыларны интернат аша озата бару хезмәтләренең республика методик берләшмәсе эшчәнлеген оештыру | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.3. | "Һөнәри ата-аналар мәктәбе" алмаштыручы ата-аналарның һөнәри осталыгын арттыру, "Очрашу бәхете" опекуннарга (попечительләргә) өйрәтү программаларын гамәлгә ашыру, "Үсентедән алып тормыш агачына кадәр" балалар йортларын тәмамлаучылар белән интернаттан соң да хәбәрдар булу | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.4. | Ата-аналар өчен бөтенроссия һәм республика форумнарында катнашу | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.5. | Татарстанның тәрбиягә бала алган этиләренең республика слетларында катнашу | Ел саен | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.6. | Тәрбиягә бала алган ата-аналарның "Йөрәкләр бердәмлеге" республика фестивалендә катнашу | Ел саен | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.7. | Татарстан Республикасының алыштыручы гаиләләре өчен "Звездный" сәламәтләндерү лагерендә балалар-ата-аналар сменасында катнашу | Ел саен | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.8. | Халыкара балаларны яклау көненә багышланган "Гаилә учагы - илһам чыганагы" дип исемләнгән яшь гаиләләрнең иҗади эшләре республика ярминкәсендә катнашу | Ел саен | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.9. | Балаларны интеллектуаль-танып-белү, сәнгать-эстетик, иҗади, хезмәт эшчәнлегенә кертү макса- | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тыннан конкурсларда катнашу | | |
| 2.10. | "Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар үзенчәлекләре" темасы буенча гомуми белем бирү мәктәпләре, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары педагоглары, һөнәри белем бирү оешмалары, балачак хокукларын саклау буенча җәмәгать инспекторлары, Татарстан республикасының тәрбиягә бала алган гаиләләрне күзәтү хезмәтләре белгечләре өчен семинарлар циклында катнашу. Аралашу ысуллары. Ярдәм күрсәтү. Хокук һәм мәнфәгатьләрне яклау" | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», опека һәм попечительлек бүлекчәсе, мәгариф учреждениеләре |
| 2.11. | Адаптация чорында һәм бала тормышының алдагы этапларында ата-аналарны һөнәри яктан тәэмин итү системасын үстерү | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.12. | Җәмгыятьтә гаилә кыйммәтләрен формалаштыру, җаваплы ата-ана булу, массакүләм мәгълүмат чараларында уллыкка алу һәм тәрбия бирүнең уңышлы мисалларын күрсәтү, методик һәм мәгълүмати материаллар, шулай ук сайтларда һәм порталларда урнаштыру:<br>Теләче муниципаль районы;<br>Татарстан Республикасы электрон мәгарифе | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 2.13. | "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, "В контакте" социаль челтәрендә, "WhatsApp" мобиль программаларында һәм скайп-аралашу ярдәмендә ата-аналарны мәгълүматлаштыру һәм аралашу | Ел дәвамында | Опека һәм попечительлек секторы |
| 3. Тәрбия өлкәсендә кадрлар потенциалын үстерү | | | |
| 3.1. | Урта һәм югары һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын, федераль дәүләт таләпләрен, сәләтле балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләү программаларын, шулай ук заманча менеджмент һәм маркетинг өлкәсендә өстенлекле идарә кадрларын әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | | |
| 3.1.1. | Педагогик кадрларның квалификациясен күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу:<br>гомуми белем мәктәпләрен тәрбияләү даирәләре, федераль дәүләт белем бирү стандартларын | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | һәм педагогның һөнәри стандартын исәпкә алып, сәләтле балалар белән программаларны да кертеп; педагогның һөнәри стандартын исәпкә алып, мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән эшләү өчен; "Мәгариф" милли проекты өстенлекләре булган идарәче кадр-лар өчен | | |
| 3.1.2. | "Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга инклюзив белем бирү" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.3. | "Махсус һәм инклюзив мәгарифтә педагогның һөнәри эшчәнлеге нигезләре" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.4. | "Акылга зәгыйфь (интеллектуаль җитешсезлекләр) булган укучылар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ФДББС БГБ гамәлгә ашыру шартларында инклюзив белем бирүнең заманча технологияләре һәм методикалары" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.5. | "Физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ФДББС БГБ гамәлгә ашыру шартларында мәгариф оешмасы белән идарә итүнең заманча технологияләре" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.6. | "Хәзерге шартларда мәгариф оешмаларының тәрбия эшләре буенча директор урынбасарының һөнәри осталыгын үстерүнең актуаль проблемалары" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.7. | "Өстәмә белем бирү методисты һәм педагогының һөнәри эшчәнлегенең оештыру-методик һәм психологик-педагогик нигезләре" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», өстәмә белем бирү учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу | | |
| 3.1.8. | "Федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру шартларында сыйныфның тәрбия эшчәнлеге системасына психологик-педагогик ярдәм күрсәтү" квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри программаларын гамәлгә ашыруда катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.9. | Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында килештерү хезмәтләре медиаторларын һәм кураторларын укыту | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.10. | Балигъ булмаганнар һәм аларның күзәтүчесезлеге арасында хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә норматив хокукый документларны өйрәнү һәм куллану буенча республика һәм муниципаль уку семинарларында катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.11. | Педагогларның, мәгариф өлкәсе хезмәткәрләренең, балаларга өстәмә белем бирүне дә кертеп, гаиләдәге иминсезлекне һәм бала белән рәхимсез мөгамәләне иртә ачыклау максатыннан, компетентлыгын арттыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.1.12. | Мәктәп татулашу хезмәтләренең медиаторларын һәм кураторларын әзерләү буенча квалификация күтәрү курсларында катнашу (күләме 24 сәгать) | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.2. | Стажировка мәйданчыклары челтәрендә, тәрбияләүнең актуаль мәсьәләләре буенча ресурс үзәкләрендә катнашу, шул исәптән оешмаларны - иң яхшы тәҗрибәне йөртүчеләрне җәлеп итеп, белем-савыктыру ялын оештыру мәсьәләләре буенча | | |
| 3.2.1. | Милли мәгариф буенча методистлар, туган тел һәм әдәбият укытучылары, әдәби түгәрәкләр җитәкчеләре өчен республика һәм муниципаль циклларда семинарларда катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.2.2. | "2014-2021 елларга балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру" ярдәмче программасы кысаларында профильле сменаларда катнашу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү" дәүләт программасын раслау турында" | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2014 елның 07 февралендәге 73 номерлы карары белән расланган "2014-2021 елларга яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү" дәүләт программасы кысаларында. | | |
| 3.2.3. | Тәрбиянең актуаль мәсьәләләре буенча база мәйданчыгы булдыруга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары арасында республика конкурсында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.2.4. | Тәрбиянең актуаль мәсьәләләре буенча гамәли семинарлар оештыру, мәгълүмати ярдәм күрсәтү | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 3.3. | Тәрбия өлкәсендәгн кадрларның һөнәри осталык конкурсларын оештыру һәм үткәрү | | |
| 3.3.1. | "Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр", "Иң яхшы педагог-психолог", "Кеше тәрбияләү", "Йөрәгемне балаларга бирәм", "Сәламәтлек укытучысы" һөнәри осталык республика конкурсларының муниципаль этабын оештыру һәм уздыру | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.3.2. | Туган телләр укытучыларының мастер-класслары - "Туган тел" Бөтенроссия конкурсының муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.4. | Тәрбия өлкәсендә, балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә һөнәри берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү | | |
| 3.4.1. | Гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчеләре республика Советы эшчәнлегендә катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.4.2. | Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары директорларының республика Советы эшчәнлегендә катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.5. | Педагогик берләшмә вәкилләре өчен яңа технологияләр, методикалар, программалар эшләү, эчтәлекне, менеджментны һәм тьюторлыкны яңарту буенча проблемалы, тематик кыска вакытлы стажировка мәйданчыклары оештыру | | |
| 3.5.1. | Теләче районы гомуми белем бирү оешмаларында үрнәк тәрбия программаларын апробацияләү | 2020 ел | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.5.2. | Тәрбиянең үрнәк программаларын тормышка ашыру | 2021 елның сентябреннән | МКУ «Мәгариф бүлеге» , мәгариф учреждениеләре |
| 3.6. | Укучыларны тәрбияләү, өстәмә белем бирү һәм социальләштерү буенча иң яхшы практикаларны һәм технологияләрне таратуда катнашу, шул исәптән рухи-әхлакый тәрбия, гаилә кыйммәтләрен саклау проблемалары буенча да (алга таба-тәрбия һәм социальләшүнең иң яхшы практикалары һәм технологияләре) | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.6.1. | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары арасында тәрбиянең актуаль мәсьәләләре буенча база мәйданчыгы булдыруга, аларның тәҗрибәсен республикага тарату буенча республика конкурсында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.6.2. | Мәктәпкәчә, гомуми, урта һөнәри, өстәмә һәм югары һөнәри белем бирү белгечләре өчен "Мәдәниятләр диалогы" Республика мәдәни-белем бирү проектында катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.6.3 | Муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү, өстәмә белем бирү учреждениеләренең методик эшләре республика конкурсында катнашу | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», өстәмә белем бирү учреждениеләре |
| 3.6.4. | "Тәрбия потенциалы: Татарстан территориясендә яшәүче халыкларның традицияләре" төбәкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.7. | Балаларда һәм яшьләрдә гражданлык позициясен формалаштыру, җәмгыятькә каршы күренешләргә тискәре мөнәсәбәт булдыру, шул исәптән экстремистик характерда тотрыклылык буенча иң яхшы практик һәм технологияләр таратуда катнашу | | |
| 3.7.1. | Терроризм һәм экстремизм идеологиясенә каршы тору буенча мәктәп укучылары, укытучылар һәм тәрбия эшләре буенча мәгариф оешмалары җитәкчеләре урынбасарлары арасында конференциядә катнашу | 2020 ел, 2022 ел | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.7.2. | "Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны һәм социаль күренешләрне профилактикалау: проблемалар һәм перспективалар" темасына түгәрәк өстәл уздыру" | 2020 ел | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 3.7.3. | Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны һәм социаль күренешләрне профилактикалау проблемалары буенча мәгълүмати-методик материаллар бастырып чыгару | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 3.8. | Балаларны тәрбияләү, өстәмә белем бирү һәм аларны социальләштерү өлкәсендә иң яхшы тәҗрибәләрне таратуда катнашу, шул исәптән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән булуын һәм аларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып | | |
| 3.8.1. | Тәрбиянең актуаль мәсьәләләре буенча база мәйданчыгы булдыруга гомуми белем бирү оешмалары арасында республика конкурсында | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу | | |
| 3.8.2 | "Мәктәп-сәламәтлек территориясе" Бөтенроссия конкурсының республика этабында муниципаль этапны оештыру һәм үткәрү | Ел саен | МКУ «Мәгариф бүлеге» |
| 4. Тәрбия өлкәсендә мәгълүмати механизмнарны үстерү | | | |
| 4.1. | Мәгариф бүлеге һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар сайтларында тәрбия мәсьәләләре буенча материаллар урнаштыру | | |
| 4.1.1. | "Татарстан Республикасы Балаларга өстәмә белем бирү навигаторы" порталында эш | Ел дәвамында | Балалар иҗат үзәге |
| 4.2. | 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләү үсеше стратегиясе чараларын мәгълүмати тәэмин итү | | |
| 4.2.1. | Тәрбия мәсьәләләре буенча бүлекләрне актуальләштерү һәм тулыландыру, мәгариф бүлегенең һәм мәгариф учреждениеләренең рәсми сайтында тематик мәгълүмат урнаштыру | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф учреждениеләре |
| 5. Татарстан Республикасында 2015-2025 елларга укучыларны тәрбияләү стратегиясен тормышка ашыру белән идарә итү | | | |
| 5.1. | 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларны тәрбияләү үсеше стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы һәм тәрбияне үстерү программаларын тормышка ашыру мониторингы | Ел дәвамында | МКУ «Мәгариф бүлеге» |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев